ГЛАВА НОВОРУССКО-МАМАТКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Молодежная, д.4,
с. Старое Русское Маматкозино, 422589

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯҢА РУС МӘМӘТХУҖАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр ур., 4 нче йорт,
Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы, 422589

Тел.: (84379) 33-6-31, факс: (84379) 33-6-31.

06.11.2019 № 2

На № ______ от ______

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 6 ноябрендә булып узган «2020 елда Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә җибәрү белән килешәсезме» соравы буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

**- Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында юлларга вак таш җәю;**

**- Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы зиратын коймалау өчен материал сатып алу, урнаштыру.**

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 158 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар санынннан 81 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 81 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегендә узган халык җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен-чын дип танырга.

2. "2020 елда Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегендә Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында яшәү урыны буенча Югары Ослан муниципаль районының Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы категория гражданнардан тыш, һәр балигъ булмаган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме? - Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында юлларга вак таш җәю;

- Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы зиратын коймалау өчен материал сатып алу, урнаштыру.

3. Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актларын теркәүгә җибәрү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче: В.В.Никитушкин**